**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 26 мартындагы 5-37 номерлы карары**

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге**
**иҗтимагый советы турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында»гы федераль закон, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советын формалаштыру тәртибе һәм аның эшчәнлеген оештыруның башка мәсьәләләре турындагы нигезләмәне (1 номерлы кушымта) расларга.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы тарафыннан җәмәгать контролен гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турындагы нигезләмәне (2 номерлы кушымта) расларга.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советын төзү тәртибе һәм аның эшчәнлеген оештыруның башка мәсьәләләре турындагы нигезләмәнең II бүлеге һәм аңа 4 номерлы кушымта «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советының беренче составы басылып чыккан көннән гамәлдән чыга дип билгеләргә.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетына 2025 елның 31 августына кадәр «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советының беренче составы формалашу турында мәгълүмати хәбәр бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 26 мартындагы
5-37 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советын формалаштыру тәртибе һәм аның эшчәнлеген оештыруның башка мәсьәләләре турындагы нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең иҗтимагый советы (алга таба – Казан шәһәре иҗтимагый советы) – Казан шәһәре җирле үзидарә органнары, Казан шәһәре территориясендә законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар эшчәнлеген күзәтү максатыннан, шулай ук алар тарафыннан чыгарыла торган актларны һәм кабул ителә торган карарларны анализлау һәм бәяләү максатыннан эшчәнлек алып бара торган җәмәгать контроле субъекты.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советы киңәшмә органы булып тора. Ул үзенең эшчәнлегендә иҗтимагый берләшмәләрдән һәм коммерциягә нигезләнмәгән башка оешмалардан булган гражданнарның ирекле рәвештә катнашуы нигезендә төзелә. Казан шәһәренең иҗтимагый советы әгъзалары үз эшчәнлекләрен иҗтимагый башлангычларда, бушлай башкаралар.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советы 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында»гы федераль законда каралган хокукларны гамәлгә ашыра һәм бурычларны үти.

4. Казан шәһәренең иҗтимагый советы юридик зат булып тормый.

5. Казан шәһәре иҗтимагый советының урнашу урыны – Казан шәһәре.

6. «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы» исеме Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары исемендә, шулай ук оешмалар исемендә файдаланыла алмый.

7. Казан шәһәре иҗтимагый советының үз исемендәге бланкы булырга мөмкин.

## 2 статья

Казан шәһәре иҗтимагый советы түбәндәге принциплар нигезендә төзелә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра:

1) кеше һәм гражданин хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең өстенлеге;

2) законлылык;

3) гражданлык җәмгыяте институтлары хокуклары тигезлеге;

4) үзидарә;

5) бәйсезлек;

6) ачыклык һәм хәбәрдарлык.

## 3 статья

1. Коммерцияле булмаган оешма Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасына бары тик бер кандидат күрсәтергә хокуклы.

2. 2005 елның 4 апрелендәге 32-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында»гы федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасына әгъзалыкка кандидатлар тәкъдим итә алмаган коммерцияле булмаган оешмалар Казан шәһәре иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатлар тәкъдим итә алмый.

## 4 статья

1. Казан шәһәре иҗтимагый советының сан буенча составы 15 кешедән тора.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советы, әгәр аның составында Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларының әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән саныннан кимендә 2/3 өлеше булса, тулы хокуклы санала.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советының вәкаләтләре чоры биш елны тәшкил итә. Ул Казан шәһәре иҗтимагый советының беренче утырышы көненнән исәпләнә. Казан шәһәренең яңа составтагы иҗтимагый советының беренче утырышы көненнән Казан шәһәренең гамәлдәге иҗтимагый советы әгъзаларының вәкаләтләре туктатыла.

4. Казан шәһәре иҗтимагый советының яңа составында алдагы составның кимендә өчтән бере үзгәртелергә тиеш.

**5 статья**

1. Казан шәһәре иҗтимагый советы составының өчтән бере гомумроссия һәм төбәкара иҗтимагый берләшмәләрнең Казан шәһәре территориясендә теркәлгән структур бүлекчәләре тәкъдиме буенча Казан шәһәр Думасы тарафыннан раслана.

Казан шәһәре Думасы, гомумроссия һәм төбәкара иҗтимагый берләшмәләрнең Казан шәһәре территориясендә теркәлгән структур бүлекчәләре вәкилләрен Казан шәһәре иҗтимагый советы составына кертү турындагы гаризаларны кабул итү туктатылганнан соң, өч ай эчендә Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларын раслый.

Казан шәһәре Думасы тарафыннан кандидатураларны карап тикшерү һәм Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларын раслау тәртибе әлеге Нигезләмәгә 1 номерлы кушымта белән билгеләнә.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советы составының өчтән бере Казан шәһәре территориясендә теркәлгән коммерцияле булмаган оешмалар, төбәк иҗтимагый берләшмәләре тәкъдиме буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Казан шәһәре Башкарма комитеты, Казан шәһәре территориясендә теркәлгән коммерцияле булмаган оешмалар, төбәк иҗтимагый берләшмәләре вәкилләрен Казан шәһәре иҗтимагый советы составына кертү турындагы гаризаларны кабул итү туктатылганнан соң, өч ай эчендә Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларын раслый.

Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан кандидатураны карап тикшерү һәм Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларын раслау тәртибе Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

3. Казан шәһәре Думасы тарафыннан расланган Казан шәһәренең иҗтимагый советы әгъзалары һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан расланган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары, Казан шәһәре территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен Казан шәһәре иҗтимагый советы составына кертү турында гаризалар кабул итү туктатылган көннән алып биш айдан да соңга калмыйча, Казан шәһәре территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр тәкъдим иткән кандидатуралар арасыннан Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары составының калган өчтән бер өлешен билгелиләр.

Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларының күрсәтелгән өчтән бере составын билгеләү тәртибе Казан шәһәре иҗтимагый советы регламенты белән билгеләнә.

4. Казан шәһәре иҗтимагый советы составы Казан шәһәре иҗтимагый советы тарафыннан «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырыла һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырыла.

## II. Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советын формалаштыру

### 6 статья

1. Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советын формалаштыру өчен Казан шәһәре Башкарма комитеты Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советын формалаштыру процедурасын башлау турында мәгълүмати хәбәрне «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгара һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыра.

Мәгълүмати хәбәрдә гаризаларны кабул итү вакыты һәм адресы, тапшырыла торган документлар исемлеге, шулай ук кирәкле башка мәгълүмат күрсәтелә.

2. Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советы, әлеге Нигезләмәнең 5 статьясындагы 3 өлешенең икенче абзацында һәм 4 өлешендә билгеләнгән очраклардан кала, әлеге Нигезләмәнең 3-5 статьяларында билгеләнгән тәртиптә төзелә.

3. Казан шәһәре Думасы раслаган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты раслаган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары тарафыннан Казан шәһәре территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр тәкъдим иткән кандидатуралар арасыннан Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советы әгъзаларының өчтән бер өлешен билгеләү тәртибе әлеге Нигезләмәгә 4 номерлы кушымта белән билгеләнә.

4. Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советына үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешма, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советын төзү турында мәгълүмати хәбәр басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә, Казан шәһәре Думасына (әлеге Нигезләмәнең 5 статьясындагы 1 өлеше белән билгеләнгән очракта), Казан шәһәре Башкарма комитетына (әлеге Нигезләмәнең 5 статьясындагы 2 һәм

3 өлешләре белән билгеләнгән очракларда) Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советына үзенең вәкилен кертү турында гариза җибәрә.

Гариза әлеге Нигезләмәнең 7 статьясындагы 3 өлешенең икенче абзацы нигезендә әзерләнергә тиеш.

5. Гаризага әлеге Нигезләмәнең 7 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән документлар теркәп бирелә.

## III. Казан шәһәренең яңа составтагы иҗтимагый советын формалаштыру

### 7 статья

1. Казан шәһәренең яңа составтагы иҗтимагый советын формалаштыру өчен Казан шәһәре иҗтимагый советы, үз вәкаләтләре чоры тәмамланырга биш айдан да соңга калмыйча, Казан шәһәренең яңа составтагы иҗтимагый советын формалаштыру процедурасын башлау турында мәгълүмати хәбәрне «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгара һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыра.

2. Казан шәһәренең яңа составтагы иҗтимагый советы әлеге Нигезләмәнең 3-5 статьяларында билгеләнгән тәртиптә төзелә.

3. Казан шәһәренең яңа составтагы иҗтимагый советына үз вәкилен тәкъдим итәргә теләк белдергән оешма «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) Казан шәһәренең яңа составтагы иҗтимагый советын формалаштыру турында мәгълүмати хәбәр басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә, Казан шәһәре Думасына, Казан шәһәре Башкарма комитетына яисә Казан шәһәре иҗтимагый советына (тиешлесенә) үз вәкилен Казан шәһәренең яңа составтагы иҗтимагый советына кертү турында гариза җибәрә.

Гариза оешманың закон буенча яисә әлеге оешманың уставы нигезендә тиешле вәкаләтләргә ия җитәкче коллегиаль органы карары нигезендә, ә коллегиаль орган булмаганда – закон буенча яисә әлеге оешма уставы нигезендә әлеге оешма исеменнән эш итәргә хокукы булган башка орган карары нигезендә әзерләнгән булырга тиеш.

4. Гаризага теркәлә:

1) оешманы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәсе;

2) оешма уставының күчермәсе һәм Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасына кандидат тәкъдим итү турында карар кабул иткән органның

вәкаләтләрен раслый торган башка документлар;

3) оешма уставы нигезендә вәкаләт бирелгән органның Казан шәһәренең иҗтимагый советы әгъзасына кандидат тәкъдим итү турындагы карары;

4) әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымта нигезендә кандидат турында анкета;

5) кандидатның Казан шәһәре иҗтимагый советы эшендә катнашуга язмача ризалыгы, шул исәптән әлеге Нигезләмәгә 3 номерлы кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.

5. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганнан соң, Казан шәһәре иҗтимагый советының әлеге Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән хокуклылыгы өчен кворум булмаса, Казан шәһәре иҗтимагый советының аннан чыгарылган әгъзасы урынына яңа әгъза Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасын раслаган Казан шәһәре җирле үзидарә органы яисә Казан шәһәре Думасы һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты раслаган Казан шәһәре иҗтимагый советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасын раслаган әгъзалары тарафыннан раслана.

Казан шәһәре иҗтимагый советының яңа әгъзасын раслау әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда башкарыла.

6. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганнан соң, Казан шәһәре иҗтимагый советының хокуклылыгы өчен әлеге Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән кворум сакланса, яңа кандидатны күрсәтү процедурасы үткәрелми.

## 8 статья

1. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе инициативасы буенча үз-үзен тарату турында карар кабул ителгән очракта, Казан шәһәре иҗтимагый советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу турында карар кабул ителгән очракта, Казан шәһәренең иҗтимагый советы:

1) әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгара һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыра;

2) «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр

басмасында (www.docskzn.ru) Казан шәһәре иҗтимагый советының 5 елга яңа составын формалаштыру турында мәгълүмат бастыра һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталына (www.kzn.ru) урнаштыра.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу турындагы карар Казан шәһәре Думасына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетына җибәрелә.

## IV. Казан шәһәре иҗтимагый советы эшчәнлеген оештыру

### 9 статья

1. Унсигез яше тулган, кимендә бер ел Казан шәһәре территориясендә даими яисә башлыча яшәүче Россия Федерациясе гражданины Казан шәһәренең иҗтимагый советы әгъзасы булырга мөмкин.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары була алмыйлар:

1) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе сенаторлары, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте әгъзалары, судьялар, Россия Федерациясе дәүләт вазифаларын биләүче башка затлар, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары, Татарстан Республикасы дәүләт вазифаларын биләүче башка затлар, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары, муниципаль вазифаларны биләүче башка затлар, федераль дәүләт хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүче затлар, муниципаль хезмәт вазифаларын биләүче затлар;

2) суд карары нигезендә хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

3) хөкем ителгәнлеге юкка чыгарылмаган яисә алынмаган затлар;

4) башка дәүләт (башка дәүләтләр) гражданлыгы, Россия Федерациясе гражданинының чит ил территориясендә яшәү өчен рөхсәт яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булган затлар.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары:

1) Казан шәһәре иҗтимагый советы уздыра торган чараларда, шулай ук карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча материаллар әзерләүдә катнашалар;

2) Казан шәһәре иҗтимагый советы утырышларының көн тәртибен формалаштыру буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3) Казан шәһәре иҗтимагый советы эшчәнлегенең теләсә кайсы мәсьәләсе

буенча үз фикерен ирекле әйтергә хокуклы;

4) Казан шәһәре иҗтимагый советы утырышында мәсьәләләр буенча фикер алышканда һәм тавыш биргәндә тигез хокукларга ия;

5) үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, иҗтимагый берләшмәләрнең, шулай ук үзләре әгъза (катнашучы) булып торган коммерциягә нигезләнмәгән башка оешмаларның карарларына бәйле түгел;

6) Казан шәһәрендә гамәлдәге законнар һәм норматив хокукый актлар нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашыралар;

7) кирәк булган очракта, Казан шәһәре иҗтимагый советы вәкаләтләре кысаларында нинди дә булса мәсьәләләрне карап тикшерү буенча Казан шәһәре иҗтимагый советының башка органнары эшен формалаштыралар һәм анда катнашалар.

4. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасы үз вәкаләтләрен раслаучы документ булып торган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасының таныклыгына ия булырга хокуклы.

5. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары Казан шәһәре иҗтимагый советы утырышларында шәхсән катнашырга тиешләр һәм үз вәкаләтләрен башка затларга тапшырырга хокуклы түгел.

6. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасы вәкаләтләре Казан шәһәре иҗтимагый советы регламентында каралган тәртиптә туктатып торыла һәм туктатыла.

**10 статья**

1. Казан шәһәре иҗтимагый советы органнары түбәндәгеләр:

1) Казан шәһәре иҗтимагый советы рәисе;

2) Казан шәһәре иҗтимагый советы рәисе урынбасарлары;

3) Казан шәһәре иҗтимагый советы сәркатибе.

Үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен Казан шәһәре иҗтимагый советы Казан шәһәре иҗтимагый советы вәкаләтләре кысаларында төрле мәсьәләләрне карап тикшерү өчен башка органнар булдыра ала.

**11 статья**

1. Казан шәһәре иҗтимагый советы эшчәнлегенең төп формасы – утырыш.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советының беренче утырышы, Казан шәһәре иҗтимагый советы составы басылып чыкканнан соң, утыз көннән дә соңга

калмыйча уздырылырга тиеш.

Казан шәһәре иҗтимагый советының беренче утырышы Казан шәһәре иҗтимагый советының яше буенча иң өлкән әгъзасы тарафыннан чакырыла һәм ачыла.

Беренче утырышта Казан шәһәре иҗтимагый советы органнары сайлана.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советы утырышлары ихтыяҗ булган саен, әмма кимендә ярты елга бер тапкыр уздырыла.

4. Казан шәһәре иҗтимагый советы утырышында аның әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

**12 статья**

1. Казан шәһәре иҗтимагый советы карарлары бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгатьләр рәвешендә кабул ителә.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советы карарлары Казан шәһәре җирле үзидарә органнары һәм аларның тиешле карарлар җибәрелгән вазифаи затлары тарафыннан мәҗбүри карап тикшерелергә тиеш. Карарларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында Казан шәһәре иҗтимагый советына язма рәвештә хәбәр ителә.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советы карарлары рекомендация характерында була.

4. Казан шәһәре иҗтимагый советының эшчәнлекне оештыру буенча карарлары Казан шәһәре иҗтимагый советы регламентында билгеләнгән тәртиптә һәм формаларда кабул ителә.

**13 статья**

1. Казан шәһәренең иҗтимагый советы Казан шәһәренең иҗтимагый советы регламентын раслый.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советы регламенты белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1) Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларының аның эшчәнлегендә катнашу тәртибе;

2) Казан шәһәре иҗтимагый советы, Казан шәһәре иҗтимагый советының башка органнары утырышларын уздыру вакытлары һәм тәртибе;

3) Казан шәһәре иҗтимагый советы рәисе вазифасына сайлану һәм аннан азат ителү тәртибе, аның вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе;

4) Казан шәһәре иҗтимагый советы рәисе урынбасарларын һәм

сәркатибен вазифаларына сайлау һәм аларны азат итү тәртибе, аларның вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе;

5) Казан шәһәре иҗтимагый советының башка органнарын формалаштыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе, шулай ук аларның җитәкчеләрен сайлау тәртибе һәм аларның вәкаләтләре;

6) Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары эшчәнлеген гамәлдәге законнар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә туктату һәм туктатып тору тәртибе;

7) Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларының әлеге Нигезләмәнең 5 статьясындагы 3 өлеше нигезендә яңа составын раслау тәртибе;

8) Казан шәһәре иҗтимагый советы, Казан шәһәре иҗтимагый советының башка органнары карарларын кабул итү тәртибе;

9) Казан шәһәре иҗтимагый советы тарафыннан җәмәгать контролен башкару формалары һәм тәртибе;

10) Казан шәһәре иҗтимагый советы эшенә гражданнарны, шулай ук вәкилләре составына кермәгән коммерцияле булмаган оешмаларны җәлеп итү тәртибе һәм аларның Казан шәһәре иҗтимагый советы белән үзара хезмәттәшлек итү формалары;

11) Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасы таныклыгы үрнәге һәм тасвирламасы (Казан шәһәре иҗтимагый советы таныклык турында карар кабул иткән очракта);

12) Казан шәһәре иҗтимагый советының эчке оештыру һәм эшчәнлек тәртибенең башка мәсьәләләре.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советы регламентына үзгәрешләр Казан шәһәре иҗтимагый советы рәисе тәкъдиме буенча яисә Казан шәһәре иҗтимагый советының кимендә 2/3 әгъзасы инициативасы буенча Казан шәһәре иҗтимагый советы карары белән раслана.

**14 статья**

1. Казан шәһәре иҗтимагый советы Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыра.

2. Казан шәһәре иҗтимагый советы эшчәнлеген оештыру, мәгълүмати һәм матди-техник яктан тәэмин итү Казан шәһәре Мэры һәм Казан шәһәре Думасы эшчәнлеген тәэмин итү идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советы эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү Казан шәһәренең чыгым йөкләмәсе булып тора.

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге
иҗтимагый советын формалаштыру тәртибе
һәм аның эшчәнлеген оештыруның башка
мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Думасы тарафыннан**
**Казан шәһәре иҗтимагый советына кандидатураларны**
**карап тикшерү һәм әгъзаларын раслау тәртибе**

1. Казан шәһәре Думасына кабул ителгән Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалыгына  кандидатлар (алга таба – кандидат) буенча тәкъдимнәр Казан шәһәре Мэры һәм Казан шәһәре Думасы эшчәнлеген тәэмин итү идарәсенә (алга таба – Идарә) теркәү өчен җибәрелә.

2. Теркәгәннән соң Идарә тәкъдимнәрне Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларына кандидатураларны алдан карап тикшерү комиссиясенә (алга таба – Комиссия) тапшыра.

3. Комиссия утырышы Казан шәһәре иҗтимагый советы составына кертү турындагы гаризаларны кабул итү туктатылганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча уздырылырга тиеш.

4. Комиссия составына Казан шәһәре Думасының барлык даими комиссияләре рәисләре керә.

5. Комиссия утырышында Комиссиянең барлык әгъзалары катнашса,  ул тулы хокуклы санала.

6. Утырышны Казан шәһәре Думасының социаль-икътисади үсеш, эшмәкәрлек һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясе (алга таба – Социаль-икътисади үсеш, эшмәкәрлек һәм муниципаль милек буенча комиссия) рәисе ача һәм алып бара.

7. Утырыш барышында Комиссия Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларына кандидатуралар буенча тапшырылган документларны әлеге Нигезләмәнең 7 статьясына (Казан шәһәре иҗтимагый советының беренче составы формалашкан очракта – 6 статьясына) туры килүгә тикшерә. Тапшырылган документлар әлеге Нигезләмәнең 7 статьясында (Казан шәһәре иҗтимагый советының беренче составы формалашкан очракта – 6 статьясында) күрсәтелгән исемлеккә туры килмәгән очракта, Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалыгына кандидатура кире кагыла.

8. Һәр кандидат буенча аерым тавыш бирү уздырыла, карар Комиссиянең барлык әгъзалары арасында гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларына кандидатлар буенча тавыш биргәндә, Комиссия әгъзалары тарафыннан кандидатларның Казан шәһәре каршындагы төрле өлкәләрдәге, шул исәптән кеше һәм гражданнар хокукларын һәм ирекләрен яклау, хәйрия эшчәнлеге өлкәсендәге казанышлары исәпкә алына.

Әгәр тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, тавышлар саны тигез булуга бәйле рәвештә, кандидатлар саны биштән артып китсә, тигез санда иң аз тавыш җыйган кандидатлар буенча кабат тавыш бирү уздырыла.

9. Комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча беркетмә рәсмиләштерелә, ул Социаль-икътисади үсеш, эшмәкәрлек һәм муниципаль милек буенча комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

Комиссия әгъзалары танышу өчен беркетмәне Казан шәһәре Думасының үзләре рәис булып торган даими комиссияләренең барлык әгъзаларына тапшыралар.

10. Беркетмә Социаль-икътисади үсеш, эшмәкәрлек һәм муниципаль милек буенча комиссия тарафыннан Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларын раслау турында Казан шәһәре Думасы карарын әзерләү һәм аны Казан шәһәре Думасының чираттагы сессиясенә карап тикшерүгә кертү өчен нигез булып тора.

11. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалыгына кандидатура кире кагылган очракта, беркетмәдән өземтә әлеге кандидатны күрсәткән коммерцияле булмаган оешмага җибәрелә.

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге
иҗтимагый советын формалаштыру тәртибе
һәм аның эшчәнлеген оештыруның башка
мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**АНКЕТА**

| Фотосурәт өчен урын (3 см x 4 см) |
|---|

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына кандидат буларак тәкъдим ителгән _______________________________________________ вәкиле
(коммерцияле булмаган оешманың тулы исеме)

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)<br>(паспорт буенча тутырыла) | |
| 2 | Туган көне, ае, елы һәм урыны | |
| 3 | Гражданлыгы | |
| 4 | Башка дәүләт (башка дәүләтләр) гражданлыгы, Россия Федерациясе гражданинының чит ил территориясендә яшәү өчен рөхсәт яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ бармы (булса – санап китегез) | |
| 5 | Белеме, кайчан һәм нинди уку йортлары тәмамлаган, диплом номерлары, диплом буенча белгечлек, диплом буенча квалификация | |
| 6 | Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме, кайчан бирелгән, диплом номерлары | |
| 7 | Эш урыны, вазифасы | |

| | | |
|---|---|---|
| 8 | Яшәү урыны буенча адресы | |
| 9 | Телефон номеры (эшнеке, өйнеке, кәрәзле) | |
| 10 | Электрон почта адресы | |
| 11 | Дәүләт һәм башка бүләкләр, мактаулы исемнәр, дипломнар һ.б. белән бүләкләнгәнме (булса – санап китегез) | |
| 12 | Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы дәүләт вазифасын биләүче зат, хакимиятнең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутаты, муниципаль вазифа биләүче зат, федераль дәүләт хезмәте вазифасын, Татарстан Республикасы яисә Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт гражданлык хезмәте вазифасын, муниципаль хезмәт вазифасын биләүче зат булып торамы (шулай булганда, вазифаны күрсәтегез) | |
| 13 | Сезнең юкка чыгарылмаган яисә алынмаган суд хөкеме бармы? | |
| 14 | Сезгә карата хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалануга сәләте чикләнгән дип тану турындагы суд карары бармы? | |
| 15 | Иҗтимагый өлкәдә эш тәҗрибәсе | |

Коммерцияле булмаган оешма
җитәкчесе вазифасы ___________ ______________________________
М.У. (имза) (фамилиясе, исеме атасының исеме)

20______ елның «____» __________

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге
иҗтимагый советын формалаштыру тәртибе
һәм аның эшчәнлеген оештыруның башка
мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**ГАРИЗА**

Мин, ________________________________________________________________,
(коммерцияле булмаган оешма вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

____________________________________________________________________
(коммерцияле булмаган оешманың тулы исеме)

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы эшендә катнашуга ризалыгымны бирәм.

_________ ______________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

20______ елның «____» __________

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы составы формалашу һәм аның эше белән бәйле рәвештә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, төгәлләштерүгә, алардан файдалануга һәм тикшерүгә) ризалык бирәм.

_________ ______________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

20______ елның «____» __________

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге
иҗтимагый советын формалаштыру тәртибе
һәм аның эшчәнлеген оештыруның башка
мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә
4 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Думасы раслаган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты раслаган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары тарафыннан Казан шәһәре территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр тәкъдим иткән кандидатуралар арасыннан Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советы әгъзаларының өчтән бер өлешен билгеләү тәртибе**

1. Казан шәһәре Думасы раслаган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты раслаган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары тарафыннан Казан шәһәре территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый берләшмәләр тәкъдим иткән кандидатуралар арасыннан Казан шәһәренең беренче составтагы иҗтимагый советы әгъзаларының (алга таба – Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары) өчтән бер өлешен билгеләү Казан шәһәре Думасы һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан расланган Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларының (алга таба – Казан шәһәре Думасыннан һәм Казан шәһәре Башкарма комитетыннан Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалары) гомуми җыелышында Казан шәһәре территориясендә теркәлгән җирле иҗтимагый оешмалар вәкилләрен Казан шәһәре иҗтимагый советы составына кертү турында гаризаларны кабул итү тәмамланган көннән биш айдан да соңга калмыйча башкарыла.

2. Гомуми җыелышта Казан шәһәре Думасыннан һәм Казан шәһәре Башкарма комитетыннан Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларының өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы була.

3. Гомуми җыелышны Казан шәһәре иҗтимагый советының Казан шәһәре Думасыннан һәм Казан шәһәре Башкарма комитетыннан булган яше буенча иң өлкән әгъзасы чакыра һәм ача.

4. Гомуми җыелыш барышында гомуми җыелыш рәисе һәм сәркатибе сайлана. Гомуми җыелыш сәркатибе беркетмә алып бара һәм тавышларны

саный.

5. Гомуми җыелыш барышында Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларына кандидатуралар буенча тапшырылган документларның Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советын формалаштыру тәртибе һәм аның эшчәнлеген оештыруның башка мәсьәләләре турындагы нигезләмәнең 6 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләренә туры килүе тикшерелә. Документлар әлеге нигезләмәнең 6 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләренә туры килмәгән очракта, Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзасына кандидатура кире кагыла.

6. Һәр кандидатура буенча аерым тавыш бирү уздырыла, карарлар җыелышта катнашучы Казан шәһәре иҗтимагый советының Казан шәһәре Думасыннан һәм Казан шәһәре Башкарма комитетыннан әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

7. Үткәрелгән гомуми җыелыш нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелә, ул гомуми җыелыш рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана.

8. Беркетмә өч көн эчендә Казан шәһәре Башкарма комитетына җибәрелә. Беркетмә нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитеты әлеге Тәртип нигезендә расланган кандидатлар исемлеген «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгара, шулай ук Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштыра.

9. Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзалыгына кандидатура кире кагылган очракта, беркетмәдән өземтә әлеге кандидатны күрсәткән коммерцияле булмаган оешмага җибәрелә.

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 26 мартындагы
5-37 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы тарафыннан җәмәгать контролен гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турындагы нигезләмә**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы җәмәгать контроле субъекты булып тора.

2. Казан шәһәре җирле үзидарә органнары, Казан шәһәре территориясендә федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар эшчәнлегенә җәмәгать контроле 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында»гы федераль закон (алга таба – 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Җәмәгать контроле 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән формаларда гамәлгә ашырыла.

4. Җәмәгать контролен гамәлгә ашырганда, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль законда каралган хокукларны гамәлгә ашыра һәм бурычларны үти.

5. Җәмәгать контролен үткәрү тәртибе Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы тарафыннан билгеләнә.

6. Җәмәгать контроле нәтиҗәләре буенча әзерләнгән йомгаклау документы «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырыла һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырыла.

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**